ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Верхний Услон

______________ ______________

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына айлык стимуллаштыручы өстәмә бирү тәртибен раслау турында» 21.08.2019 ел, № 808 Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"» 22.04.2024 елгы 95-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты:

1. "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына айлык стимуллаштыручы өстәмә бирү тәртибен раслау турында" 21.08.2019 ел, № 808 Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«**яшь белгеч - төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча беренче тапкыр эшкә урнаша торган, шул исәптән төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча уку чорында алынган хезмәт стажы булган һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуын тәмамлаган 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы ("Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында" 30.12.2020 № 489-ФЗ Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе М.М. Черменский